ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

ФЕВРАЛЬ, 2018нче ел

№6 (36)

**ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!**






**14—Гашыйклар көне**

**23— Ватанны саклаучылар көне**

23 нче февраль көнне илебез төп бәйрәмнәрнең берсе – Ватанны саклаучылар көнен билгеләп үтә. Ил барда – егет хур булмас, диләр, илебез сагында торучы кыю, курку белмәс егетләребез барында илебез халкы тыныч йоклар, күгебез гел аяз булыр. Хөрмәтле ир-атларыбыз! Барыгызны да Ватанны саклаучылар көне белән эчкерсез котлыйбыз! Сезгә һәм сезнең гаиләләргә тыныч күк йөзе, нык сәламәтлек, уңышлар һәм иртәгесе көнгә ышаныч телибез!

Сезгә һәрвакыт ихтыяр көче, гаилә бәхете юлдаш булсын! Тормыш сынауларына бирешмичә, һәрвакытта да чын ирләр булып калуыгызны телибез! ***Әтиләре, абыйлары үрнәгендә патриотик рухта тәрбияләнгән яшь егетләребезгә хәрби хезмәтләрен үтәгәндә, туган якта калган якыннарының тынычлыгын саклап, үзләрен яхшы яктан гына күрсәтерләр дигән ышаныч белдерәбез.***

**Гөлинә Закирова**

**«Без бергә”** дип исемләнгән Республика конкурс – фестивале яңа талантлар ачты. 12 нче февраль көнне шул уңайдан мәктәбебездә концерт оештырылды. Укучылар татар халык фольклорының төрләре буенча чыгыш ясадылар.






**Бу санда:**


| | |
|---|---|
| Сафта йөрү һәм жыр смотры | 2 |
| Батырлар онытылмый | 3 |
| Якыннан танышыйк! | 4 |
| Конкурслар | 5 |
| Әтиләр конференцясе | 6 |
| Парламент дәресләре | 6 |
| Котлыйбыз! | 7 |

## 20 нче февраль көнне мәктәбебездә <u>Сафта йөрү һәм жыр смотры</u> узды.













## 14 нче февраль— гашыйклар көне

Дөньяның матурлыгы саф хисләрдә чагылыш таба. Ә беренче саф хисләр мәктәп елларында бөреләнә.



## Бәйрәмнән фоторепортаж




















Гражданлык-патриотик тәрбия айлыгы кысаларында 21 февральдә **<u>“Жиңү вальсы”</u>** дигән хәрби жырлар конкурсы үтте. Конкурста барлык сыйныф укучылары да теләп катнашты. Алар һәрберсе үз номинацияләрендә жиңүче дип табылды.

22 нче февраль көнне Айрат Каюмович житәкчелегендә өлкән сыйныфлар арасында ярыш оештырылды . Һәрбер уен егетләрнең армия хезмәтенә әзерлекләренә нигезләнеп, заманча жиһазлар белән оештырылып алып барылды. Нәтиҗәдә ике команда да жиңүче дип табылды.

## Якыннан танышыйк!





**Укучыларның сорауларына мәктәпнең данын республика күләмендә үткәрелгән олимпиадада яклаган укучылар Зарипова Зилә, Гафурова Алия, Гайсина Гөлшат җавап бирәләр.**

_-Район күләмендәге олимпиадада җиңүче булганыңны белгәч Зилә нинди хисләр кичердең?

- Әлбәттә, беренче чиратта шатлык хисе кичердем.

- Республикада мәктәп данын яклау 7 нче сыйныф укучысы өчен авыр булмадымы?

- Авыр түгел иде, чөнки мин бик нык әзерләндем. Өстәмә әдәбияттан нык файдаландым. Терминнарны ятладым.

- Сезнең уңышларыңда кем зур роль уйнады.

- Беренче чиратта укытучым Сафиуллина Резедә Дамир кызы һәм безне әзерләүче укытучыбыз Әһлиуллина Гөлүсә Дамир кызы, минем гаиләм, чөнки эшне башкарганда бик зур таяныч кирәк.

- Алия, син беренче тапкыр республика олимпиадасына барганда ничә яшьтә идең?

- 14 яшьтә 8 нче сыйныфта идем.

- Анда яңа иптәшләр белән таныштыңмы?

-Әйе, алдагы елда танышкан иптәшләрем белән быел да очраштык . Хәбәрләшеп, сөйләшеп торабыз.

- Олимпиада эшләрен эшләгәндә нинди хис– тойгылар кичердең?

- Каушата. Син үзеңнең район данын якларга тиеш икәнлегеңне тоясың . Бар булган белемеңне эшкә җигәсең. Баллар җыярга тиешсең . Быел минем балларым призлы урын яулар өчен бернечәгә генә җитеп бетмәде. Ләкин алай да мин үземнең нәтиҗәләрем белән канәгатьмен..

- Анда яшәү шартларыннан сез канәгатьме?

- Әйе, Яшәү шартлары бик әйбәт итеп оештырылган.

- Сезнең белән без бик матур әңгәмә алып бардык. Аның өчен сезгә бик зур рәхмәт.

- Үзегезгә дә зур рәхмәт.. Бик матур сораулар әзерләгәнсез.

**Әңгәмәне «Яшь журналистлар» төркеме алып барды.**

# Әфганстан - йөрәк ярасы

1 нче февраль көнне Совет солдатларын Әфган җиреннән чыгарылуга 29 ел уңаеннан,сугышчы- интернационалист Нуруллин Тәлгат Мингалим улы призына хоккей турниры булып узды. Очрашу боз өстендә башланып китте. Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге җитәкчесе Линар Нурислам улы Маняпов бәйрәмне ачып җибәрде. Шулай ук бу очрашуга Нуруллин Тәлгатнең туганнары, дуслары чакырулы иде. Фома, Чулпан, Киекле, Кизләү, авыл мәктәпләреннән килгән уенчылар хоккей уенын башлап җибәрделәр. Икенче өлеше “Әфганстан -йөрәк ярасы” исеме астында кунаклар белән түгәрәк өстәл артында дәвам итте.Балаларның чыгышлары, солдат хатлары, сугышчыларның мавыктыргыч сөйләүерен еламый карарга мөмкин түгел иде.





## Фома мәктәбе укучылары «Ялкын» журналы  февраль ае чыгарылышының иң яхшы язма авторлары




кәтелг

**“Ялкын” сайтында февраль санының иң яхшы язмасын сайладык. Тавыш бирүдә 800дән артык кеше катнашты?**
**Безнең актив авторыбыз Алинә Нямаеваның мәкаләсе иң-иңе дип табылды.**
**Котлыйбыз, Алинә??** *(«Ялкын» журналы сайтыннан алынды)*

Икенче урында  Әһлиуллин Аяз .

**Бу айда кемнең язмасы күбрәк ошады?**

- «Игелек кыл да суга сал...» Алинә Нямаева (49%, 404 Голосов)
  «Батыр ватанны саклый» Аяз Әһлиуллин (44%, 363 Голосов)

### Игелек кыл да суга сал

Күптән көтелгән тәнәфескә чакырып, кыңгырау яңгырады. Букчаңны асып, йөгереп өйгә кайтып китәргә дә яисә мәктәп янындагы таудан чанада шуарга да мөмкин. Ә менә без, Фома мәктәбендә укучы балалар, вакытны тагын да игелекле гамәлләргә багышларга булдык: көрәкләр тотып, өлкән авылдашыбызга булышырга киттек. Әйе, авылларда гына түгел, илебездә дә ярдәмгә мохтаҗ әбибабайлар саны елдан ел арта бара.

Шулай итеп без ялгыз яшәүче ??? әбинең хәлен белешергә һәм көчебездән килгәнчә ярдәм итәргә теләдек. Ул ялгыз, балалары юк, туганнары читтә яши. Әби безне бик шат йөз белән каршы алды. Тыл ветеранына әллә ни зур ярдәм дә итмәдек инде ул көнне: гөлләренә су сибеп, ишегалдын кардан чистарттык. Әмма шул хезмәтебезгә дә бик сөенде әбекәй. ??? әби тумыштан сөйләшә белмәсә дә, безгә рәхмәт укып туялмавын, изге теләкләр теләвен ым-ишарә белән аңлатты. Кешегә, бигрәк тә ярдәмгә мохтаҗ өлкән кешегә күп нәрсә кирәкми.

“Җылы сүз – җан азыгы” дип юкка гына әйтмиләр шул. Әби өеннән чыгып киткәндә үзебезгә дә бик рәхәт булды. Сыйныфташларым белән кар бәрешә-бәрешә уйнап, табигатьнең матурлыгына сокланып кайттык. Матур эшләр матур хисләр генә тудыра шул!



### Батыр Ватанны саклый

Кышның соңгы ае булса да, февральдә безнең мәктәптә эш кызу була. Бигрәк тә Ватанны саклаучылар көне җиткәндә.

23 февраль - ил батырларына хөрмәт бәйрәме. Ватанны сакларга әзер булган кеше гайрәтле, гыйлемле, тәвәккәл зат булырга тиеш. Ир-атларга шундый бурыч йөкләнгән дә инде. Мәктәптәге кызларыбыз, безне сынау өчен, бәйге уздыра, ә без үзебезне Ватан саклаучы солдат итеп хис итәбез. Кулга “повестка” алгач, кайсы командага эләккәнебезне беләбез, Устав белән танышабыз. “Теория дәресләре”ндә армия тормышына кагылган викторина сорауларына җавап бирәбез. Элек яшь егетне рыцарьлыкка кабул итү өчен, аның җиде төрле һөнәрне тиешенчә үзләштерүе мөһим булган: атка атланып йөрү, фехтование, сөңге белән эш итү, шашка уйнау, йөзү, аучылык, шигырьләр язу. Бездән нәкъ шуларны эшләтмәсәләр дә, кызларның биремнәре төрле һәм кызыклы. Морзе әлифбасын кулланып, элемтәче дә булабыз, өчпочмаклы хат язабыз, казармадагы эшләрне башкарабыз, физик күнегүләрне санап та тормыйм. Бәйге ахырында, тирләп-пешеп тезелеп басабыз да, жюри нәтиҗәсен көтәбез. Җиңгәннәр дә, җиңелгәннәр дә шат, чөнки үзең җиңелсәң дә, дустың җиңгән булып чыга.

Инде традициягә әйләнгән этиләр конференциясе көне аеруча күңелле үтә. Этиләребез алдында сынатмаска тырышып, җырлап-тезелеп басып күрсәтәбез (смотр строя и песни)? Ул көнне мәктәпнең иң талантлы җырчы, биючеләре дә чыгыш ясый әле. Этиләребезгә үз кулларыбыз белән ясаган бүләкләрне тапшырабыз. Өлкәннәр “Бала тәрбияләүдә этиләрнең роле” темасы астында сөйләшү оештыралар. Аннары инде этиләр чыгышын карыйбыз. Алар, командаларга бүленеп, хоккей уйный. Бусы гаҗәп кызык була инде. Эштән башка нәрсәне белмәгән этиләр уйнаганны, егылганнарын күреп шатланабыз, борчылабыз. Конференциядә катнашкан этиләребезгә ихтирамыбыз тагын да арта. Иганәче этиләр ярдәм иткәнлектән, ярышта җиңүчеләргә грамоталар бирергә, этиләрне кайнар чәй эчерергә дә мөмкинлек табабыз. Бәйрәмнән һәркем канәгать кала.

# Конкурслар






Әле быел гына 1 нче сыйныфка укырга керүче Валиуллин Нияз укытучысы Ахметова Рузилә Әсхәт кызы җитәкчелегендә февраль аенда гына да берничә конкурска катнашып өлгерде. «Минем мәктәпкә куркынычсыз юлым» исемендәге конкурста «Маршрут бите» номинациясендә катнашты, аның эше районда күргәзмәгә куелды. 27 нче февраль көнне Түбән Кама шәһәрендә үткәрелгән «Дебют в науке» республика эзләнү эшләре һәм проект-лары буенча фән-практик конференциясендә катнашып сертификат алып кайтты. Котлыйбыз сине, Нияз! Әфәрин!!!

**10 февраль көнне Нурлат шәһәрендә “Татарстан чаңгы юлы – 2018” массакүләм чаңгы ярышлары узды.**

Бу көнне мәктәп укучыларыннан алып, муниципаль хезмәткәрләр, җитәкче урыннарда эшләүчеләр, ветераннар, ата-аналар һәм дә балалар да чаңгы юлына басты. Безнең мәктәп тә бу ярыштан читтә калмады. Бертуган Вилдановлар Рәзил белән Рәмзил, Аглиуллин Аяз, Закирова Гөлинә, Сөнгатуллина Рәзилә кебек укучыларыбызның бу ярышта бик теләп катнашуы яшьләрнең спортка битараф булмавын күрсәтеп тора. Табигать-анабыз да, кояшлы матур көн бүләк итеп, спорт сөючеләрне сөендерде.

«**Елның сыйныф җитәкчесе һәм ел укытучы-сы – 2018” конкурсы**

Февральдә Нурлат районы Якушкино урта мәктәбендә “Елның сыйныф җитәкчесе” һәм «Ел укытусысы –2018» бәйгесенең беренче туры үтте. Безнең мәктәпне рәсем һәм технология укытучысы **Садртдинова Рузилә Нурислам кызы** тәкъдим итте .Ул куст ярышында 3 нче при-злы урынга лаек булды. Ел укытучысы бәйгесенә башлангыч сыйныф укытучысы Гирфанова Ралия катнашты.



# Парламент дәресләре

Мәктәбебезнең өлкән сыйныф укучылары арасында “2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсеш стратегиясе” темасына парламент дәресе узды. Дәрескә авыл җирлеге советы депутаты Абдрахманов Рәшит Һадиевич катнашты. Җәмгыять белеме укытучысы Гөлфия Фәхриева җитәкчелегендә укучылар тагын дистә елдан соң җөмһүриятебез һәм районыбызның киләчәгенә сәяхәт кылдылар. Ә аларның туган илләре, җирләре һәм мәктәпләрен тагын да матуррак итеп күрәсе килә. Яшь буынның фикер-тәкъдимнәренең бик әһәмиятле булуы тагын бер кат ассызыкланды.





26 февраля в целях реализации плана работы МБУ ДО «Центр детского творчества» НМР РТ, активизации деятельности первичных коллективов детских общественных объединений РДШ и органов ШУС, вовлечения представителей РДШ, президентов ШУС в общерайонные мероприятия, провели учебу актива РСДОО «Новое поколение». Из нашей школы участвовали Хайбуллина Алсу (ученица 10 класса) и Садретдинова Рузиля (ученица 9 класса).

## Әтиләр конференциясе

21 нче февраль көнне мәктәптә Әтиләр конференциясе булып узды. Конференция гаилә тәрбиясенең бала тормышында мөһим роль уйнавы турында барды. Укучылар һәм әтиләр командасы арасында мини-КВН үтте. Бу уенда әтиләрнең тәҗрибәсе, укучыларның өлгерлеге билгеләп үтелде. Әтиләрне балаларының укуы, тәрбиясе турында югары дәрәҗәдә хәбәрдар булуы күңелне сөендерде. Без әтиләрне һәм мәктәбебезнең ир-егетләрен бәйрәмнәре белән котлыйбыз!









**Февраль аенда туган көннәрен билгеләп үтүче**

**директорыбыз**

**Сафиуллин Хәлим Салихович,**

**укытучыбыз:**

**Садртдинова Рузилә Нурисламовна**

Сезне туган көнегез белән чын күңелдән котлыйбыз. Сезгә нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы, гаилә шатлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр, ак бәхетләр, балаларыгызның һәм оныкларыгызның күңел җылысын тоеп, игелекләрен күреп, бәхетле озын гомер кичерүегезне телибез. Киләчәгегез җыр кебек матур, кояш кебек якты булсын. Туачак таңнарыгыз һәрвакыт нурлы, күк йөзегез һәрвакыт аяз булсын. Гел шулай елмаеп, кешеләрне сөендереп яшәгез!






Февраль аенда туучы

кадерле укучыларыбыз:

*Салахова Әдилә, Галимов Инсаф, Нямаева Алина, Минегулов Илсур*!

Сезнең барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар, нык сәламәтлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын!

**Бу сан өчен мәктәпнең «Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**

**“ К Ө З Г Е ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Фәхретдинова Равидә Нәгыймовна

**Урынбасары:** Әһлиуллин Аяз

**Дизайнер**: Гафурова Алия

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Әһлетдинова Гөлләр, Гайнуллина Алия, Гайсина Вероника, Закирова Гөлинә, Масгутова Гөлназ, Хайруллина Әдилә, Хисматова Зәринә.